| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>САЛИХОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САЛИХ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 августа 2018 г. с. Новые Чути № 7

Муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында"
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районы сайтында «авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

З. С. Галләметдинов

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге

Муниципаль хезмәтләр

1. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аерым категория гражданнарны исәпкә кую.
2. Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү.
3. Социаль наем шартнамәсе нигезендә гражданга муниципаль милектәге торак урыны бирү.
4. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү.
5. Капиталь төзелеш объектына почта адресын бирү (шул исәптән тәмамланмаган төзелеш объектына).
6. Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү.
7. Васыятьнамә таныклыгы һәм ышанычнамәләр буенча.
8. Җир кишәрлегенә белешмә, йорт хуҗаларына белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү.